ГЛАВА СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД БОЛГАР» СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШЛЫГЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«БОЛГАР ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15 » июль 2024 ел Болгар ш. № 6

2024 елдан 2034 елга кадәр Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең җылылык белән тәэмин итү схемасы проекты (актуальләштерелгән җылылык белән тәэмин итү схемасы проекты) буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 пунктының 6 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2012 елның 22 февралендәге 154 номерлы РФ Хөкүмәте Карары нигезендә җылылык белән тәэмин итү, аларны эшләү һәм раслау тәртибе һәм «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең җылылык белән тәэмин итү схемасы проекты (актуальләштерелгән схема проекты) буенча 2024 елдан 2034 елга кадәр, 2024 елның 22 июлендә 11-00 сәгатькә гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.
2. ТР Спас муниципаль районы башкарма комитетының актлар залын (Болгар шәһәре, Пионер урамы, 19 йорт) гавами тыңлаулар уздыру урыны итеп билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеген 2024 елдан 2034 елга кадәрге чорга җылылык белән тәэмин итү схемасы проекты Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://spasskiy.tatarstan.ru/ урнаштырырга.
4. Тәкъдимнәр һәм кисәтүләр, шулай ук гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар эш көннәрендә 8-00 сәгатьтән 17-00 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул итеlә: ТР, Спас районы, Болгар шәһәре, Пионер урамы, 19 йорт

(тел.30361), яисә электрон почтага bolgarispkom@mail.ru күрсәтелгән язма рәвештә.

5. Әлеге карарны "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге торак пунктлары территориясендәге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru/ һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы Ф.В.Мөхәммәтов

СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БОЛГАР»